| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.06.2019 Казан ш. № 168

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты каршында Журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләрен раслау турында

«Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 48 статьясы нигезендә
б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты каршында Журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләрен расларга.

2. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

3. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары А.Л.Штромга йөкләргә.

Рәис в.б. А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 28.06.2019 № 168 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты каршында Журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләре

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Кагыйдәләр «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 48 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты каршында массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын аккредитацияләү тәртибен регламентлый (алга таба – аккредитацияләү, Дәүләт комитеты).

1.2. Аккредитацияләү 6 айлык срокка башкарыла һәм әлеге вакыт эчендә даими булып тора. Массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясенең ихтыяры белән аккредитацияләү конкрет редакция биремен үтәү өчен кирәкле срокка (вакытлыча аккредитация) тормышка ашырылырга мөмкин.

## II. Аккредитация алу хокукы

2.1. Милек формасына һәм гамәлгә куючылары составына бәйсез рәвештә массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре, шул исәптән чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары, аккредитация үтүгә хокуклы. Чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары журналистын аккредитацияләү өчен Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршында аккредитация узуны раслый торган документларның күчермәләре таләп ителә.

## III. Аккредитацияләү тәртибе

3.1. Аккредитацияләүгә гариза Дәүләт комитетына массакүләм мәгълүмат чарасы җитәкчесе имзасы белән түбәндәге срокларда тапшырыла:

алдагы чордан алда килгән айның 20 көненә кадәр даими аккредитацияләнү өчен;

редакция йөкләмәсен үти башлаганчыга кадәр 2 эш көненнән соңга калмыйча вакытлыча аккредитацияләнү өчен.

Даими һәм вакытлыча аккредитацияләнүгә гариза Дәүләт комитетына күрсәтелгән гаризаның алыну фактын, датасын һәм вакытын расларга мөмкинлек бирүче теләсә кайсы ысул белән тапшырыла.

3.2. Гаризада журналистның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), аның вазыйфасы, кесә һәм эш телефоннары, электрон почта адресы, массакүләм мәгълүмат чарасының тулы исеме, массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык датасы һәм номеры күрсәтелә.

Вакытлыча аккредитацияләнүгә гаризада шулай ук редакция йөкләмәсе һәм аны үтәү чоры күрсәтелә.

Чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары журналистын аккредитацияләү өчен өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршында аккредитация узуны раслый торган документларның күчермәләре теркәлә.

3.3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетына әлеге Кагыйдәләрнең 3.1 пунктында күрсәтелгән сроктан соң кергән, әлеге Кагыйдәләрнең 3.2 пункты таләпләренә җавап бирми торган гаризалар каралмый.

3.4. Аккредитацияләү (аккредитацияләүдән баш тарту) турында карар Дәүләт комитеты рәисе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба – рәис) тарафыннан яисә аның кушуы буенча Дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары (алга таба – рәиснең беренче урынбасары) тарафыннан гариза кергән көннән бер эш көненнән дә соңга калмыйча кабул ителә.

Мондый карар рәиснең яисә рәиснең беренче урынбасарының тиешле боерыгы чыгарылган көннән башлап киләсе эш көненнән соңга калмыйча гаризаны җибәргән массакүләм мәгълүмат чарасына аның редакция тарафыннан алыну фактын, датасын һәм вакытын раслау мөмкинлеген бирә торган теләсә нинди ысул белән җиткерелә.

3.5. Массакүләм мәгълүмат чарасы махсус характерда (реклама, белешмә, күңел ачу) булган очракта, аккредитацияләүдән баш тартыла.

3.6. Аккредитацияләү турында гаризаны карау, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясенә кабул ителгән карар турында хәбәр итү Дәүләт комитетының матбугат сәркатибе тарафыннан башкарыла.

## IV. Аккредитацияләнгән журналистларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Аккредитацияләнгән журналистлар түбәндәгеләргә хокуклы:

чарада катнашырга;

чара турында Дәүләт комитеты карамагында булган рәсми документларның (көн тәртибе, матбугат релизлары, мәгълүмати-белешмә, статистик, аналитик) күчермәләрен алырга;

бастырып чыгару өчен билгеләнгән мәгълүматибелешмә материаллар белән танышырга;

Россия Федерациясе законнарында каралган башка хокуклар.

4.2. Аккредитацияләнгән журналистлар бурычлы:

чара регламентын үтәргә һәм аның барышына тыкшынмаска, әгәр ул массакүләм мәгълүмат чаралары өчен махсус оештырылмаган булса;

чарада катнашучылар эшчәнлегенә комачауламаска;

мәкаләләрендә (эфирдагы эшендә) Дәүләт комитетыннан бирелгән матбугат релизларын, мәгълүмати-белешмә, статистик, аналитик материалларны кулланганда, мәгълүмат чыганакларына сылтама ясарга;

үзенең һөнәри эшчәнлеген тормышка ашырганда Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында чынбарлыкка туры килми торган мәгълүматларны таратмаска.